СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

# КАРАР

19.09.2025 ел № 5 Чепья авылы

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы Регламентынв өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карар кабул итте: Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының 20.12.2010 №17 карары белән расланган Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:: «5. Карар кабул иткәндә хәлиткеч тавыш хокукына ия депутатларның "хуплыйм" һәм "каршы" бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.».

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Чепья
авыл җирлеге башлыгы ________________ А. Г. Нотфуллин